* **Әлмәт шәһәре «Ямашнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе прогимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Вилданова Алия Илгиз кызы төзеде**

# * Бәхетле очрак бәйгесе

3 нче сыйныф укучылары

## ***Беренче бүлек***

***1.Г.Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигырендә малай эткә нинди сүзләр әйтә?***

-Ах, юләр маэмай! Өйрән яшьләй, зурайгач җайсыз ул....

-Ах, юләр маэмай! Эшлә яшьләй, зурайгач җайсыз ул...,

- Ах, юләр маэмай!Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул....

***2. Әминә Бикчәнтәеваның “Тәмле сүз” хикәясендә кунак апа ни өчен Гөлкәйне “тәмсез телле” дип шелтәли?***

А) Гөлкәй Рәйсәне чәй эчәргә чакырмый.
Б) Гөлкәй Рәйсәгә ачуланып дорфа итеп дәшә.
В)Гөлкәй әнисенә дорфа итеп дәшә.

***3.Мирсәй Әмир “Җиргән” хикәясендә кайсы халыкның чит телләрне остарак өйрәнүе турында язган?***

А) татар
Б) рус
В) чуваш
Г) мордва

***3.Подъездда тапкан песигә балалар нинди исем бирәләр?***

Мияу
Тарзан
Ак песи
Васька

***4. Г.Тукайның “Умарта корты һәм чебеннәр” мәсәлендә төп теманы билгеләгез:***

1.Бал кортларын сакларга кирәк.
2.Чебеннәрне чит илләргә куарга тырышырга.
3.Хезмәт иткән кешеләр үз илләрендә кадерле булалар.

***5.”Сабан туенда” хикәясендә Салих нинди музыка уен коралында уйный?***

-фортепианода
-гармунда
- скрипкада
-курайда

***7. Ф.Яруллинның “Кояштагы тап” хикәясендә малай нинди начарлык эшләгән?***

***6. Р.Вәлиеваның “Туган көндә” хикәясендә Фәриданең туган көнен ни өчен әнисе уздырмаска булган?***

## *Икенче бүлек*

*1. Мәгънәсе буенча сүзләрне тап.*

1. Алмагачның җимеше.
2. Аркадагы һәм яндагы тиресе энәләр белән капланган кечкенә җәнлек.
3. Агач яки куакның җир өстеннән башлап очына кадәр ботаклар җибәрә торган өлеше, төп сабагы.
4. Нинди дә булса текстны эченә алган, битләре билгеле бер тәртипкә бергә җыйналып төпләнгән басма.
5. Йозакны бикли һәм ача торган махсус тимер җайланма.
6. Судья, хөкем итүче.

## *2. Мәгънәсе буенча килеп чыккан алынма сүзләрне тап*

Театр өчен сәхнә әсәрләре язучы.

Кара чәчле, кара кашлы кеше.

Әйбер (зкспонатлар) саклый торган махсус урын, бина.

Хәл ителергә тиешле мәсьәлә.

Ике ягына агачлар утыртылган сукмак.

## 4. Фразеологизмнарны гади бер сүз белән алыштырып языгыз.

**Авыз пешү —**
**куян йөрәк —**
**түбәсе күккә тию —**
**кот очу —**
**авызыннан энҗе чәчү —**
**ачык авыз —**
**авыз турсайту —**
**теңкәгә тию —**

Сүзләр: куркак, аптырату, курку, шатлану, үпкәләү, надан, матур сөйләү, алдану.

## *5. Омонимнарны тап.*

Ат муенында була, эшләп арыгач була, каникулга чыккач була_______________

Шул сүз белән кеше битен һәм бер санны атыйлар, суда хәрәкәт итәргә дә шул сүзне әйтеп кушалар_________________

Җимеш орлыгын яисә үзәген атыйлар, өстән аска таба барырга кушу, билгеле бер урын, җир_________

## *6. Мәкальләрне дәвам итеп язып бетер.*

· Ялкаулык — хурлык, тырышлык — -------------.
· Чисталык — сәламәтлек------------ .
· Ипи — иң зур ---------- .
· Эшләп ашасаң, һәр ризык балдай --------- ------- .
Телләр белгән-илләр ----------- -------------.
Бауның озыны, сүзнең ------------ -------------.
Туган телем-иркә --------------.
Яшьлегеңдә өйрәнмәсәң, картлыгыңда -------------.

## *7. Капитаннар ярышы-табышмаклар чишү*

Вак кынадыр үзләре
Ялтырыйдыр күзләре

Ул булганда көн була,
Булмаганда төн була

Йөз кат кием,
барысы да төймәсез

Үскәндә-яфрагын,
Үскәч, тамырын ашыйлар.

Әрекмәндәй зур колак,
Аяклары бер колач,
Борыны җиргә тигән,
Килгән ул ерак җирдән

Үзе мәчегә охшаган,
Сырлы-сырлы тун кигән.
Ул безнең зоопаркка
Җылы яклардан килгән.

**8. Кроссворд чишү.**
**9. Ике сүздән бер сүз ясау.**

**10. Укытучылар өчен тур. Тюркизмы в русском языке.**

-Какая улица в Москве названа татарским словом
А) Мичурина
Б)Ломоносова
В)Арбат

-Как называется верхняя одежда для мужчин и женщин?
А) плащ
Б) бишмет
В) зипун

**Какое слово заимствовано из татарского языка?**

а)чемодан
б)сундук
в)сумка

**Как называли переводчика в старину?**

а) баламут
б) тылмач
в) бурлак

**Какое слово заимствовано из татарского языка?**

а) колбаса
б) лимон
в) халва

а)тюльпан
б)жасмин
в)роза